| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**16.08.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 121** |

Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.О. Котельниковның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2015 елның 21 июлендәге 59-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең (2 нче кушымта) автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен (1 нче кушымта) кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр арасында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында аларның Башкарма комитетлары аша килешүләр ( 3 нче кушымта) төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә кабул ителгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла,

шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс акчаларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

4. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. 2015 елның 2 февралендәге 485 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советы
2016 елның 16 августындагы
121 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

**Кабул ителә торган вәкаләтләр Исемлеге**

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2016 елның 16 августындагы
121 номерлы карарына
2 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче, алар Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләрне тапшыра торган муниципаль берәмлекләр исемлеге**

1. Васильево штп
2. Карамалы Тау штп
3. Әйшә авыл җирлеге
4. Бишнә авыл җирлеге
5. Большие Ключи авыл җирлеге
6. Олы Шырдан авыл җирлеге
7. Күгеш авыл җирлеге
8. Мулла Иле авыл җирлеге
9. Осиново авыл җирлеге
10. Раифа авыл җирлеге
11. Өтәшкә авыл җирлеге

Зеленодольск муниципаль районы
Советы
2016 елның 16 августындагы 121
номерлы карарына
3 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы_____________җирлек Башкарма комитеты арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында**
**Килешү**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Башкарма комитет җитәкчесе йөзендә _____________, Устав нигезендә эш итүче, бер яктан, __________________җирлек Башкарма комитеты, _________________ йөзендә икенче яктан, бергә аталучы "Яклар" 2015 елның 21 июлендәге 59-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасы җирле үзидарә турында "Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законының 17 пунктның 3 өлешенә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына таянып, әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр:

1 статья. Килешү Предметы

1.1 Әлеге Килешү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына _____________________________ җирлек башлыгы Башкарма комитет вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен тапшыруны беркетә.

1.2 ________________җирлек Башкарма комитеты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыра:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

2 статья. Тапшырылган вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү

2.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.2 Яклар әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгели.

3 статья. Якларның хокуклары һәм бурычлары:

3.1. ______________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты:

3.1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрне үтәвен тикшереп тора. Ачыкланган бозулар

ачыкланган очракта ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен мәҗбүри булган язма күрсәтмәләр бирә.

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетыннан әлеге Килешүнең 1 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге максатларга бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалану белән бәйле кирәкле мәгълүмат, материаллар һәм документлар соратып ала;

3.1.3. Әлеге Килешүнең 1 статьясында күрсәтелгән соңгы тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына консультация һәм методик ярдәм күрсәтә;

3.2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты:

3.2.1. Әлеге Килешүнең 1 статьясында каралган вәкаләтләрне, гамәлдәге законнар таләпләренә туры китереп, тиешенчә гамәлгә ашыра;

3.2.2. ______________ җирлек Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча консультация һәм методик ярдәм күрсәтү ала;

3.2.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыру өчен махсус вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләүне тәэмин итә;

3.2.4. ______________ җирлек Башкарма комитеты рәсми мөрәҗәгать буенча бирелгән вәкаләтләрне үтәү белән бәйле документлар һәм башка мәгълүмат тәкъдим итә .

## 4 статья. Якларның җаваплылыгы

4.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

4.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як әлеге Килешү буенча кушымтада каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

4.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

4.4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, бу вәкаләтләр финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә җаваплылык тота.

## 5 статья. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

5.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты әлеге Килешүнең 1 өлешендә каралган эшләрне башкаруны, контрольдә тоту Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап бирү юлы белән башкарыла.

## 6 статья. Гамәлдә булу вакыты, нигезләр һәм туктату тәртибе

Килешүнең гамәлдә булуы

6.1. Әлеге Килешү 2016 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты 2016 елның 31 декабренә кадәр билгеләнә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

6.3.1. Яклар килешүе буенча.

6.3.2. Берьяклы тәртиптә түбәндәге очракта:

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәртү;

- әлеге Килешү нигезендә Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве;

- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр авыл җирлекләре Башкарма комитетлары тарафыннан аеруча мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәлерәк гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.4. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә берьяклы тәртиптә язма рәвештә җибәрелә. Килешү күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәргәннән соң 30 көн узгач өзелгән дип санала.

## 7 статья. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

7.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр, Якларның сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

7.2. Килешүгә ирешмәгән очракта, бәхәсне суд тәртибендә, законнар нигезендә карап тикшерергә тиеш.

## 8 статья. Йомгаклау шартлары

8.1. Әлеге Килешү, ике нөсхәдә төзелгән, Якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия.

8.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, Яклар тарафыннан өстәмә килешүләр имзалау юлы белән гамәлгә ашырыла.

8.3. Әлеге Килешүдә җайга салынмаган мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таяна.

8.4. Әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр үткәрү юлы белән яки суд тәртибендә хәл ителә.

8.5. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

- Кушымта: бюджетара трансфертлар күләме.

## 9. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе | ____________________ җирлек<br>Башкарма комитеты җитәкче |
| _________________/___________/ | ____________/_______________/ |
| «____» _____________ 2016 ел | «____» ______________ 2016 ел |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты һәм
_________________ җирлек  Башкарма
комитеты арасында
Килешүгә карата кушымта

**Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме**

Әлеге Килешү предметы  буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен ______________________җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына  бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме  ____________ сум тәшкил итә.